# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

30 октябрь 2023 ел № 7

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Чыршы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 27 октябрендә 16 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез 2024 елда Каенлык авыл җирлеге территориясендә Чыршы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

а) Чыршы торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен ремонтлау;

б) Чыршы торак пунктында юлларны ремонтлау асфальт өслек белән капланган -

в) кышкы юлларны тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту, тракторчының хезмәт хакы;

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 260 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 132 кеше, бу 50,8 %ны тәшкил итә.

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 131 катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Чыршы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

“Сез 2024 елда Чыршы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

- “а) Чыршы торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен ремонтлау;

б) Чыршы торак пунктында юлларны ремонтлау асфальт өслек белән капланган -

в) кышкы юлларны тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту, тракторчының хезмәт хакы”

- дигән мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип санарга.

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенлык авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Әминов